КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 11 июль г.Казань № 809

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» 2006 ел, 24 март, 126 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 3 июнь, 370 нче; 2009 ел, 6 апрель, 203 нче; 2012 ел, 23 февраль, 153 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 25 август, 611 нче; 2015 ел, 23 сентябрь, 701 нче; 2015 ел, 1 декабрь, 911 нче; 2016 ел, 22 июнь, 425 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 998 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче; 2019 ел, 11 март, 168 нче; 2019 ел, 13 март, 181 нче; 2019 ел, 20 декабрь, 1173 нче; 2020 ел, 2 июнь, 461 нче; 2020 ел, 5 ноябрь, 999 нчы; 2020 ел, 16 декабрь, 1141 нче; 2021 ел, 20 февраль, 92 нче; 2021 ел, 10 май, 322 нче; 2021 ел, 12 июль, 567 нче; 2021 ел, 28 сентябрь, 918 нче; 2022 ел, 3 март, 194 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1479 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 пунктта:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакынд» 2006 ел, 7 июнь, 275 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинетының 2007 ел, 16 февраль, 47 нче; 2007 ел, 14 июнь, 235 нче; 2008 ел, 26 ноябрь, 832 нче; 2009 ел, 27 февраль, 115 нче; 2009 ел, 8 апрель, 209 нчы; 2009 ел, 21 август, 571 нче; 2010 ел, 2 апрель, 229 нчы; 2015 ел, 4 февраль, 61 нче; 2015 ел, 12 март, 146 нчы; 2016 ел, 13 май, 305 нче; 2016 ел, 26 май, 359 нчы; 2016 ел, 19 октябрь, 762 нче; 2018 ел, 15 февраль, 90 нчы; 2018 ел, 24 март, 166 нчы; 2020 ел, 12 май, 379 нчы; 2021 ел, 17 февраль, 85 нче; 2022 ел, 7 март, 203 нче; 2022 ел, 13 август, 815 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәгә, 4 пунктның өченче абзацындагы «дәүләт хакимияте» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак урыны белән тәэмин итү хокукын гамәлгә ашырган ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга бер мәртәбә акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2023 ел, 1 февраль, 79 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 13 июнь, 714 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 3 пункттагы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин